ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 август 2021 ел № 5526

Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы куркынычсызлык режимы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә, фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чаралары үткәргәндә кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын һәм сәламәтлеген тәэмин итү, муниципаль милеккә, юридик һәм физик затлар милкенә зыян китерүгә юл куймау максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибен, 1 нче кушымтада каралганча;

2) халыкның Яр Чаллы шәһәре территориясендә махсуслаштырылган кибетләрдә яки кибетләрнең махсуслаштырылган бүлекләрендә ирекле сату рөхсәт ителә торган I-III класс куркынычлы (куркыныч зона радиусы 0,5 тән 20 метрга кадәр) көнкүреш пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыннары исемлеген, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәре территориясендә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорында халыкның пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыннарын билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 7004 номерлы;

2) «Башкарма комитетның Яр Чаллы шәһәре территориясендә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорында халыкның пиротехник эшләнмәләрдән

файдалану урыннарын билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 7004 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 15 декабрендәге 6769 номерлы;

3) «Башкарма комитетның Яр Чаллы шәһәре территориясендә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорында халыкның пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыннарын билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 7004 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 13 декабрендәге 7811 номерлы;

4) «Башкарма комитетның Яр Чаллы шәһәре территориясендә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорында халыкның пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыннарын билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 7004 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 17 декабрендәге 7558 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 19 августындагы
5526 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип, фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чаралары үткәргәндә кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын һәм сәламәтлеген тәэмин итү, муниципаль милеккә, юридик һәм физик затлар милкенә зыян китерүгә юл куймау максатында, Яр Чаллы шәһәре территориясенең җәмәгать урыннарында салютлар, фейерверклар үткәрү һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләрдән файдаланып оештыру һәм үткәрүгә таләпләрне билгели.

2. Нигезләмәнең гамәлләре, аларның оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, физик затларга, юридик затларга, салютлар, фейерверклар оештыру һәм үткәрүне, шулай ук Яр Чаллы шәһәренең җәмәгать урыннарында пиротехник эшләнмәләрдән файдалануны гамәлгә ашыра торган вазыйфаи затларга кагыла.

2 бүлек. Әлеге тәртиптә файдаланыла торган төп билгеләмәләр

3. Фейерверк оештыручы дигәндә, массакүләм чараның инициаторы һәм аны оештыру һәм үткәрүне финанс һәм башка яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы, фейерверк үткәрүгә фейерверк оештыручы белән шартнамә төзүче юридик яки физик зат дип аңларга кирәк.

4. Фейерверк оештыручы дигәндә, пиротехник эшләнмәләрне куллануга Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан бирелгән техник регламент нигезендә лицензиясе булган юридик зат яки шәхси эшмәкәр аңлашыла.

5. Фейерверк оештыру (үткәрү) дигәндә, кеше күпләп җыела торган урыннарда чаралар үткәргәндә пиротехник эшләнмәләр куллану аңлашыла.

3 бүлек. Салютлар, фейерверклар үткәрү, шулай ук пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыны һәм вакыты

6. Таможня союзының «Пиротехник эшләнмәләрнең куркынычсызлыгы турында» техник регламенты буенча I класс куркынычка

туры килә торган пиротехник эшләнмәләрне (шартлавыклар һәм бенгаль утларыннан тыш) куллану тыела:

- бүлмәләрдә, биналарда һәм теләсә нинди функциональ билгеләнештәге корылмаларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча өстәмә инженерлык-техник чаралар комплексы эшләнгән махсус сәхнә эффектлары, профессиональ пиротехник эшләнмәләр һәм ут эффектларын кулланудан тыш;

- шартлау куркынычы һәм янгын куркынычы булган объектлар территорияләрендә, тимер юл, нефтьүткәргеч, газүткәргеч һәм югары вольтлы электр тапшыру линияләре полосаларында;

- түбәләрдә, өслекләрдә, балконнарда, лоджияләрдә һәм биналар (корылмалар) фасадларының чыгып торган өлешләрендә;

- митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар үткәрү вакытында;

- Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектлары, тарихи һәм мәдәният һәйкәлләре, зиратлар һәм культ корылмалары, заповедниклар, заказчылар һәм милли парклар территорияләрендә

- алардан файдаланганда куркынычсызлыкны тәэмин итәргә мөмкинлек бирми торган һава торышы шартларында;

- пиротехник эшләнмә җитештерүче тарафыннан билгеләнгән яшь чикләүләрен үтмәгән затларга;

- «Төнге вакытта гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2013 елның 26 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, төнге вакытта.

7. Кеше күпләп җыела торган урыннарда I-III класс куркынычлы пиротехник эшләнмәләрдән файдаланып фейерверклар әзерләнгәндә һәм үткәргәндә:

- кулланыла торган пиротехник эшләнмәләргә инструкция таләпләрен исәпкә алып, фейерверк үткәрү мөмкин булган өстәмә инженерлык-техник чаралар эшләнергә тиеш. Алар фейерверк эшләнмәләрен урнаштыру пунктлары күрсәтелгән схеманы үз эченә алырга, куркынычсыз зона чикләрен, шулай ук пиротехника продукциясен саклау һәм аны утильләштерү урыннарын күрсәтеп, биналарга, корылмаларга кадәр куркынычсыз араны күздә тотарга тиеш;

- тамашачылар җил искән якта булырга тиеш. Фейерверк үткәрү урыннарыннан биналарга һәм тамашачыларга кадәр куркынычсыз ара кулланыла торган пиротехник эшләнмәләр инструкциясе таләпләрен исәпкә алып билгеләнә;

- пиротехник эшләнмәләр җибәрелә торган мәйданчыкларда тәмәке тарту һәм ут ягу, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне караучысыз калдыру тыела;

- фейерверклар оештырганда куркынычсызлыкны тәэмин итү фейерверкны оештыручы һәм үткәрүчегә йөкләнә;

- пиротехник эшләнмәләрдән файдаланганнан соң территория карап

тикшерелергә һәм кулланылган, кулланып булмаган пиротехник эшләнмәләрдән һәм аның куркыныч элементларыннан чистартылырга тиеш.

8. Биналарда һәм корылмаларда Таможня союзының «Пиротехник эшләнмәләрнең куркынычсызлыгы турында» техник регламенты буенча II класс куркынычлы пиротехник эшләнмәләрне куллану рөхсәт ителә.

9. Биналарда һәм корылмаларда кешеләр күпләп җыела торган концерт һәм спорт чараларын үткәргәндә II класс куркынычтан югары булмаган махсус сәхнә эффектларын, пиротехник эшләнмәләрне һәм ут эффектларын куллану рөхсәт ителә. Махсус сәхнә эффектларын, пиротехник эшләнмәләрне һәм ут эффектларын кулланып чаралар оештырганда оешма җитәкчесе (милекче) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарының XXIV бүлегенә таяна, 14 календарь көн эчендә Башкарма комитетның район хакимиятенә һәм янгын күзәтчелеге органнарына планлаштырыла торган чара турында хәбәр итә.

10. Әлеге тәртипнең таләпләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган Янгынга каршы режим кагыйдәләрен бозган өчен, фейерверк оештыручы, шулай ук фейерверк үткәрүче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 19 августындагы
5526 номерлы карарына
2 нче кушымта

Халыкның Яр Чаллы шәһәре территориясендә махсуслаштырылган кибетләрдә яки кибетләрнең махсуслаштырылган бүлекләрендә ирекле сату рөхсәт ителә торган I-III класс куркынычлы (куркыныч зона радиусы 0,5 тән 20 метрга кадәр) көнкүреш пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен билгеләнгән урыннар исемлеге

1. «Җиңү» паркы» – чыршы белән янәшәдә әйләндереп алынган спорт мәйданчыгы («Шахмат-шашка клубы» административ бинасыннан 300 м га көнбатыштарак, 20/07 торак йортыннан 750 метрга көньяктарак).

2. Шәһәр пляжы янындагы мәйданчык (Раскольников урамы, 60 йорт буенча 3 этажлы Таунхаустан 350 м көньяк-көнбатыштарак), 38/05 торак йортыннан 400 м көнбатыштарак).

3. «Төзүче» спорт мәктәбе» БЯСМ МАӨББУ стадионы артындагы мәйданчык (Мәләкәс елгасы яр буенда «Төзүче» спорт мәктәбе» БЯСМ МАӨББУ стадионыннан 300 м көнчыгыштарак, «Яр Чаллы сәнгать колледжы» ДАҺББУ дан 350 м көньяк-көнчыгыштарак).

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева